БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2025 Баулы шәһәре №164

Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф сеткасы таралмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен күтәрү һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 14 апрелендәге 226 номерлы Карары нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының «Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 20 апрелендәге 73 номерлы карарына (Баулы шәһәр Советының

28.09.2018 №90, 28.08.2020 №140, 22.02.2022 №55, 26.10.2022 №70, 16.12.2022 №81, 13.06.2024 №132, 08.11.2024 №141 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә бюджет өлкәсен аерым оештыруның структур бүлекчәсе җитәкчесенең вазыйфаи окладлары күләменә күчерелә, аларга бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый, ул 15 389 сум тәшкил итә.»;

3 пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Баулы шәһәр Мэры,
шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров